**Эш тәҗрибәсе**

Соңгы елларда җәмгыятебез зур үзгәрешләр кичерә. Тиз адымнар белән барган фәнни-технологик прогресс, кеше тормышына мәгълумати технологияләрнең киң колач җәеп үтеп керүе мәгариф өлкәсенә дә яңалыклар алып килә, уку - укыту процессына да тәэсир ясый. Бүгенге көндә югары әхлаклы, тәвәккәл холыклы, мөстәкыйль фикер йөртеп һәр эшкә иҗади якын килә белгән, югары сөйләм культурасына ия булган, белемле яңа шартларында яши алган сәламәт шәхес тәрбияләү – заман мәктәбенең бурычлары. Бу таләпләрне тормышка ашырыр өчен бүгенге заман укытучысы интерактив методлар һәм ысуллар кулланып, яңалыкка омтылу мәҗбүри.

Мин, Айнуллова Гөлчәчәк Нияз кызы Казан шәһәренең 131 нче лицеенда татар теле һәм әдәбиятын укытам. Шулай ук сыйныф җитәкчесе дә.

Коммуникатив методның төп максаты - сөйләмгә мотивация тудыру ярдәмендә өйрәтү. Балаларны сөйләшергә өйрәтү өчен иң уңышлылардан коммуникатив метод дип санаганга, бу аралашуга, җанлы сөйләмгә таяна торган методик алымнар комплексын еш кулланам. Бу метод беренче планга укучыларны сөйләшергә өйрәтүне куя, ә теоретик белешмәләр сөйләм процессында, текстны анализлау нәтиҗәсендә чыгарыла.

Рус телле балаларны татар сөйләменә өйрәтү процессы коммуникатив технология нигезендә циклылыкка корылган. Цикл – уку материалын диалогик, монологик, ягъни мөстәкыйль сөйләм дәрәҗәсенә житкерү өчен кирәк булган дәресләр. Дәрес тибы буенча бу дәресләр лексик күнекмәләр формалаштыру, грамматик күнекмәләр формалаштыру, лексик - грамматик күнекмәләр формалаштыру, диалогик-монологик сөйләм дәресләре дип атала.
Рус телендә сөйләшүче укучыларны татар теленә өйрәтүнең беренче адымнарыннан ук балаларны чит сөйләмне тыңларга һәм аңларга өйрәтергә кирәк. Шуңа да дәресләрдә аудирование зур урын алып тора. Аудирование - әйтелә торган сөйләмне ишетү, тыңлау һәм аңлау.

Укытучы һәм сыйныф җитәкчесе буларак мин дә укучыларымның төп компетенцияләрен үстерүгә йогынты ясарлык методларны өйрәнәм.

Проблемалы укыту технологиясе – укучының укытучы белән системалы рәвештә яңа проблемаларны чишү юлларын эзләүне оештыручы педагогик процесс. Әдәби әсәрне анализлау технологиясе аша куллану бик отышлы.

Әңгәмә алымы. Әдәбият дәресләрендә әңгәмә алымын отышлы. . Проблемалы сораулар куеп, укучылар арасында бәхәс тә туа. Бәхәс итү юллары аша укучы үз фикерен аңлатырга һәм расларга өйрәнә.

Әдәби әсәр текстын анализлаганда, куелган проблемалы сорау һәм биремнәргә җавап эзләгәндә, укучылар тормыш тәҗрибәсен туплап баралар. Үз эшенә контроль ясый һәм бәя бирә белү күнекмәсе формалаша.

Проектлы эшчәнлек.

Балаларның белемнәрен интеграцияли, танып белү эшчәнлеген арттыра, иҗади һәм тикшеренү күнекмәләрен үстерә. Компьютерны дөрес куллану кебек дөньякүләм проблеманы хәл итүгә юл ача.

1. Тикшеренү проекты. Ул укучыларның актуаль проблеманы аңлау һәм аны хәл итүгә юнәлтелгән..

2. Иҗади проект. Бу төр проект укучыларда иҗади һәм креатив фикер йөртү сәләтен үстерә.

3. Гамәли юнәлешле проект. Бу төр проект укучыларда практик күнекмәләрне формалаштыра.

4. Мәгълүмати проект. Бу проект мәгълүматны җиткерүгә юнәлгән.

Проблемалы укыту аша укучыларның төп компетенцияләрен формалаштыру һәм шул рәвешле ныклы белем бирү мәгълүмати технологияләрсез күз алдына китерү авыр. Татар теле дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Проектор белән эшләү дәрестә укытучының бик күп вакытын файдалы үткәрергә ярдәм итә

Дәрестә проектор куллануның психологик ягы да көчле. Хәзерге балаларга тузып-искереп беткән картина, төссез рәсемнәр урынына интернеттан алынган рәсемнәрне карау күңеллерәк тә, мавыктыргыч та. Дәрестә компьютер куллану яки өйдә балаларның компьютер белән артык мавыгулары турында төрле бәхәсле фикерләр ишетергә мөмкин. Чамасын белмичә компьютер уеннары белән утырган балалар да күп.

Проекторны уку дәресләрендә дә, язу дәресләрендә дә кулланылырга мөмкин. Әмма аның һәр дәрестә куллану максаты төрлечә була. Татар теленә, ягъни язуга тукталыйк. Безнең төп максат: хәрефләрне дөрес һәм матур итеп, юлдан аска төшеп яки өскә менеп китмичә хатасыз язарга өйрәтүАларда матур язуга кызыксыну туа, игътибарлылыклары көчәя. Күрмә диктантлар, иҗади диктантлар яздыру проектор ярдәмендә искиткеч тиз эшләнелә.

Рәсемнәр буенча иҗади эшләр башкару (хикәяләр төзү, җөмләләр уйлап яздыру һ.б.) шулай ук бик уңай.

Инде уку дәресләренең төрле этапларында проекторны куллануга кайбер мисаллар карап китик.

I. Сүзлек эше.

1 нче вариант. Сүзләрне аңлатмалары белән язып кую.

Егълап – (елап) – плача, яшьләр түгелде – потекли слезы; башаклар –колосья; тиргә төшерә – потеть.

2 нче вариант. Сүзләрне рәсемнәре белән күрсәтү.

3 нче вариант. Цифрлы электрон чыганаклар куллану. Бу очракта мин «Электрон белем бирү» порталындагы әзер теманы ачам. Мәсәлән: «Табигать» темасы. Барысы 11 күнегү бар. Шуның беренчесе – татарча-русча сүзлек. Кирәк булса, рус сүзләрен күрсәтмичә дә торып була.

Монда 18 тема бар. Шуннан кирәкле тема буенча рәсемнәр, сүзлек эше буенча күнегүләр, ишетеп аңлау өчен күнегүләр (аудирование), кызыклы грамматик биремнәр, диалоглар, кроссвордлар сайлап алырга мөмкин. Дәреснең файдалы вакытын әрәмгә үткәрмичә тиз генә бер күнегүдән икенчесенә күчеп була.

II. Актуальләштерү. Белемнәрне актуальләштерү укучылар белән әңгәмә рәвешендә уза. Мондый әңгәмә сорауларын слайдлар белән тулылындыру отышлы. Боларда схемалар, таблицалар рәвешендә бирелгән үткән дәресләрдә алган, укучыларга таныш булган теоретик материал бирелә. Үтелгән материалны тизрәк искә төшерү өчен узган дәрес презентацияләрен дә файдаланырга була, бу очракта ассоциатив хәтер эш итәчәк. Кайбер слайдларда җавап табу өчен өстәмә сораулар да язылган булырга мөмкин, әмма җаваплар үзе язылмый. Яңа материалны аңлаткан чакта презентация бирелешенең мөмкинлекләре бик зур.

Слайдларны текст белән чуарламаска кирәк. Анда, башлыча, даталар, исем, термин, рәсем, схема, зур булмаган таблицалар, кыскача тезислар языла. Слайдның масштабы, төсе фоны алдан уйланыла.

Дәрес темасын аңлату – тулаем презентация белән барырга тиеш дигән сүз түгел. Аңлату барышында дәреслек белән дә эшләнелә, тактага һәм дәфтәрләргә дә языла, кагыйдәләр белән дә эш ителә. Бу очракта слайдларда бары тик терминнар яки кагыйдәләр генә языла. Дәрес материалын беренчел ныгытканда әңгәмә һәм тестлар белән эш итү кулайрак.

Әгәр презентация дәреснең барлык этапларында да кулланылса, аның аерым өлешләрен төрле фоннарда күрсәтү отышлырак. Тик шунысы бар: дәрестә слайдларны кирәгеннән артык күп куллану белән мавыкмаска кирәк, шул ук вакытта бертөрле дә булмасын – менә шул чакта гына аларны куллану уңай нәтиҗә бирәчәк. Мисал китереп үтәм. «Песнәк» хикәясен укырга әзерләнәбез. Башта кыш турында кыска әңгәмә үткәрергә кирәк. Моның өчен мин слайдларда кыш турында шигырь юллары язылган рәсемнәр күрсәтәм. Аннан интерактив китапка кереп, Р.Миңнуллинның шигырен тыңлыйбыз. Кышкы

көннәрдә кошларга азык табуы читенләшә. Бездә кышлаучы һәм җылы якларга китүче кошларны ачыклыйбыз. Экранда таблица күрсәтелә.

III. Яңа теманы аңлату. Текст өстендә эш. Текстны укыр алдыннан әйтергә кыен сүзләр экранда күрсәтелә һәм укытучы укыганны укучылар укып баралар. Күрү һәм ишетү хәтере бергә кулланылганлыктан, укучылар сүзләрнең дөрес әйтелешен яхшы хәтерләп калалар. Хикәя авторының һәм ул язган китапларның сурәтләре күрсәтелә. Теманы аңлату барышында проектор ярдәмендә төрле кроссвордлар, ребуслар һәм башваткычлар чишәргә бик уңайлы. Бу укучыларның текст белән кызыксынуларын арттырырга ярдәм итә.

IV. Ныгыту. Дәреслектәге биремнәр белән эшләгәннән соң, өстәмә биремнәрне проектор ярдәмендә башкару балаларның теманы ныграк истә калдыруларына ярдәм итә.

Төп максат: укучыларда фәнни фикерләү, иҗади эшләү сәләтен үстерү, тәрбия эшендә югары нәтиҗәләргә ирешү, җәмгыятьтә үз урыннарын таба алырлык иҗади шәхес тәрбияләү бурычы тормышка ашырыла.

Компьютер технологияләреннән уңышлы файдалану, тел һәм әдәбият фәненә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучыларда ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли, аның байлыгын, матурлыгын, фикри тирәнлеген ачып бирә, аны мәдәниятле итә, һәрьяклап үстерә, шәхес итеп тәрбияли. Укытучы укучыга тормышта үз урынын табарга ярдәм итүче төп Безнең укучыларыбыз бөтен яктан да үрнәк балалар булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде.

Укчыларны тел өйрәтүгә кызыксындыру максатыннан мин дәресләремдә төрле аудио, видеолар кулланам. Татар теле дәресләрен нәтиҗәле итүдә, уку – укытуның сыйфатын яхшыртуда компьютер технологияләреннән, аерым алганда, Microsoft Word, Microsoft Excel, Microsoft Power Point кебек гамәли программалардан, электрон почта, Skype, Twitter һәм гомумән Интернет челтәреннән файдаланам. Шулай ук 2014 нче елда Education First кысаларында гамәлгә кергән “Ана теле” он-лайн мәктәбенә кереп укучылар белән төрле-төрле мультимедиа биремнәрен (анимация, тавыш, интерактив биремнәр һ.б.) эшлим һәм уку-укыту процессын тагын да кызыклырак, мавыктыргычрак һәм тәэсирлерәк итәм.

Әдәбият дәресләрендә өстәмә материал буларак интерактив китаплар, аудиоресурслар кулланам һәм укучыларның кызыксынуын арттырам. Мәсьәлән, соңгы елларда чыккан Г.Тукай, герой-шагыйрь М.Җәлил, Р.Фәхретдин, Г.Исхакый тормышлары һәм иҗатларына багышланган методик әсбапларда фотосурәтләр, сәнгать әсәрләре, истәлек-хатирәләр, дөнья күргән барлык әсәрләре, хатлары, белешмәләр, тест сораулыклары бирелә.

Шәхси якын килеп эш итү уңай нәтиҗә бирә. Сәләтле укучылар белән төрле эш формалары алып барыла. Татар теленнән  олимпиадага әзерләнү түгәрәкләре эшләп килә. Шулай ук лицейда викториналар, иҗат кичәләре, конкурслар уздырылды. Ел саен “Татар теле атналыгы”н үткәрәбез. Укучыларыбыз фәнни-конференцияләрдә, олимпиадаларда актив катнашалар. 2016, 2017 нче елларда призерларым булды. Җитәкләгән 10 А сыйныфымда бер укучы математика, алты укучы химия фәннәреннән республика һәм бөтенроссия олимпиадлары җиңүчеләре.

Метод һәм технологияләрне тулысы белән тормышка ашырыр өчен зур көч кирәк һәм әзерлек кирәк.Шуңа күрә  төрле курсларда булам, семинарларда катнаштым.

Бүгенге укучыларның гыйлем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик гыйлем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк.